**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 19 май

№ 328

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2016 ел, 15 апрель, 231 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2016 ел, 15 апрель, 231 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әгәр тиешле урман кишәрлегенең кырыйдагы агачларына кадәр ераклык җирләрендә икедән артыграк катлы капиталь төзелеш объектлары булган торак пункты чигеннән кимендә 100 метр һәм җирләрендә ик һәм азрак катлы капиталь төзелеш объектлары булган торак пункты чигеннән кимендә 50 метр тәшкил итсә, урман кишәрлегенә турыдан-туры тоташучы җир кишәрлекләрен бүлеп биргәндә катгый рәвештә янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге норматив документлар нигезендә эш итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков